# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы
Пыжмара авыл җирлеге составына керүче Пыжмара торак пункты

20октябрь 2022 ел №6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35нче маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Пыжмар торак пунктында гражданнар җыены карар итте:

1. «2023 елда гражданнарның үзара салымын Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең Пыжмара торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр кешедән 500 (Биш йөз) сум күләмендә кертергә (I төркем инвалидлар өчен; үз-үзләренә хезмәт күрсәтә алмый торган гражданнар; балигъ булмаган балалар тәрбияләүче ялгыз ата-аналар (законлы вәкилләр); Россия Армиясе сафларында вакытлы һәм контракт хезмәте үтүче хәрби хезмәткә чакырылучыларның 90% ы күләмендә ташлама каралган).

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
- Г.Тукай, Яңа, Мөлеков, Пыжмара авыллары урамнарына вак таш җәю.»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында, Балтач муниципаль районы сайтында http://baltasi.tatar.ru урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче:
ТР Балтач муниципаль районы
Пыжмара авыл җирлеге башлыгы Р. Х. Җәләев